МИНИСТЕРСТВО
ЦИФРОВОГО РАЗВИТИЯ
ГОСУДАРСТВЕННОГО
УПРАВЛЕНИЯ,
ИНФОРМАЦИОННЫХ
ТЕХНОЛОГИЙ И СВЯЗИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ ИДАРӘСЕН
ЦИФРЛЫ НИГЕЗДӘ
ҮСТЕРҮ, МӘГЪЛҮМАТ
ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ ҺӘМ
ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.05.2026 Казан ш. № п/131

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының 2022 елның 3 октябрендәге п/265 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының "Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмә раслау турында" 2022 елның 3 октябрендәге п/265 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының 2023 елның 25 апрелендәге п/96 номерлы, 2023 елның 23 августындагы п/187 номерлы, 2024 елның 28 июнендәге п/134 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмәдә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Комиссия Министрлык боерыгы белән төзелә, аның нигезендә Комиссиянең составы һәм аның эш тәртибе раслана, Комиссия рәисе, аның

урынбасары, секретаре билгеләп куела һәм Комиссиянең башка әгъзалары билгеләнә.

Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмый торганда аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.»;

2.2 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) министр урынбасары (Комиссия рәисе), Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче зат (Комиссия рәисе урынбасары), Министрлыкның дәүләт хезмәте кадрлар бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты (Комиссия секретаре), кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегеннән, Министрлык эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлегеннән, Министрлыкның башка бүлекчәләреннән министр билгеләгән дәүләт хезмәткәрләре;»;

3.1 пунктта:

«а» пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәткәре тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәдә каралган белешмәләрне төгәл яисә тулы итеп тапшырмавы турында;»;

«б» пунктчасының икенче абзацында «үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләрне» сүзләрен «үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләрне, шулай ук керемнәре, үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында» сүзләренә алмаштырырга;

3.15 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәгә туры китереп, дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең төгәл һәм тулы булуын билгеләргә;»;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының

дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе составында:

Комиссия составыннан М.Н.Гыймранованы, И.С.Начвинны чыгарырга;

Комиссия составына кертергә:

Афанасьева Светлана Николаевнаны – Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге башлыгы, Комиссия секретарен;

Яковлев Альберт Валерьевичны – Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасары, Комиссия рәисен.

Министр И.С.Начвин